**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Державина, д.12 а
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Державино урамы, 12 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**2021елның 15 феврале** **4 номер**

# КАРАР

## «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасының «Авыл җирлекләренең заманча йөзе» ведомство максатчан программасында катнашуы турында

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Рунар Рөстәм улы Хамаев, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге депутаты Матвеев Александр Николаевич тәкъдим иткән мәгълүматны, Сокуры авыл җирлеге территориясендә «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасының «Авыл җирлекләренең заманча йөзе» ведомство максатчан программасы турында һәм Сокуры авылында төзелеш кирәклеге турында мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң:

-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авылында су алу скважиналарын бораулауны күздә тоткан су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү-2 берәмлек, насос станцияләрен урнаштыру - 2 берәмлек, суэтем башняларын урнаштыру - 4 берәмлек һәм 5,579 км суүткәргеч челтәр сузу.

-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авылында һәм Столбище авылында ташландык суларны агызу системаларын төзү, анда ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү - 3,3336 к. һәм тупланма савытлар урнаштыру күздә тотыла.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуров авыл җирлеге советы нигезендә КАРАР ИТТЕ**:**

1. Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасының «Авыл җирлекләренең заманча йөзе» ведомство

максатчан программасында катнашуга сайлап алынган объектларга документация әзерләргә;

- икътисадның тотрыклы, динамикалы үсеше һәм гражданнар өчен имин мохит булдыру нигезендә халыкның тормыш сыйфатын күтәрүне тәэмин итәргә.

1. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:/pravo.tatarstan.ru адрес буенча бастырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге комитеты җитәкчесе Хамаев Рунар Рөстәм улына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районының**
**Сокуры авыл җирлеге советы**
**Башлыгы урынбасары** **А.А.Хәлитов**